**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БОРДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

29.08.2019 ел — Борды авылы — № 16

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегенең 2019 нчы елның 1 нче яртыеллыгында бюджет үтәлеше турында хисап проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү хакында

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегенең 2019 нчы елның 1 нче яртыеллыгында бюджет үтәлеше турында хисап проекты буенча » карар проекты буенча фикер алышуда Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге халкының катнашу хокукларын саклау максатында, Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегенең 2019 нчы елның 1 нче яртыеллыгында бюджет үтәлеше турында хисап проекты буенча» карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.
2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында 2019 елның 29 августыннан да соңга калмыйча урнаштырырга .
3. Билгеләргә:
- халык тыңлауларын бер көндә үткәрергә;
- халык тыңлауларын үтәкәрү вакытын: 2019 елның 13 сентябрендә 14.30 сәгатьтә;
- үткәрү урынын: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Борды авылы, Школьная урамы, 3нче йорт (Борды авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы)
- проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү, халык тыңлауларында катнашу өчен чыгыш ясау хокукы белән гаризалар бирү өчен адрес: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Борды авылы, Школьная урамы, 3нче йорт (Борды авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы) (эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр).
- халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты – 2019 елның 12 сентябренә кадәр.
4. Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Башкарма комитетына «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы — Р.Н.Абдульманова